Балалар өчен Изге Язма

тәкъдим итә

# Гайсә Мәсихнең тууы



Автор: Edward Hughes
Рәсемнәр: M. Maillot
Alastair Paterson
Кемнәр өчен: E. Frischbutter; Sarah S.
Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com
Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

BFC
PO Box 3
Winnipeg, MB R3C 2G1
Canada

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.

Борын-борын заманда Раббы Алла Мәрьям исемле яшь гыйффәтле яһүд кызы янына Җәбраил фәрештәне җибәрә. Ул аңа: “Синең улың туар, һәм син аңа Гайсә дип исем куштырырсың. Ул Аллаһы Тәгаләнең Улы дип аталыр. Аның патшалыгының ахыры булмаячак”,- дип әйтә.



“Ничек шулай була ала, минем бит әле ир-ат белән якынлык кылганым юк?”  дип сорый аптырап калган кыз.  Фәрештә Мәрьямгә: “Сиңа Аллаһы Тәгаләнең кодрәте төшәчәк, шуңа күрә син тудырачак Бала изге булыр һәм Аллаһы Улы дип аталыр”, - дип җавап бирә.



Шул чакта Фәрештә Мәрьямгә кардәше Элисабетның картайган көнендә балага узуы турында әйтә.  Бу да бер могҗиза була.  Озак та үтми Мәрьям Элисабет янына бара.  Бергәләшеп Аллаһыга шөкер итәләр.



Мәрьям Йосыф исемле кеше белән ярәшкән була. Мәрьямнең бала көткәнлеге турында белгәч, Йосыф кайгыра башлый. Чөнки баланың әтисе башка берәүдер дип уйлый.



Төшендә Аллаһы фәрештәсе Йосыфка әлеге баланың Аллаһы баласы булуы турында әйтә.  Йосыф Мәрьямгә Гайсәне карашуда ярдәм итәргә тиеш була.



Йосыф Аллаһыга ышана һәм аңа буйсына. Ул шулай ук үз илендәге кануннарга да буйсынып яши. Яңа канун аркасында ул Мәрьям белән, салымнарны түләү өчен,



үзенең газиз Бәйтлехем каласына кайтып китә.



Мәрьямнең бала
тудырыр вакыты җитә.
Ләкин Йосыф үзенә
беркайдан да бүлмә
таба алмый.  Кунак
йортында аларга
урыннар калмаган
була.

Ниһаять, Йосыф ат абзарын табып ала. Шунда Сабый Гайсә дөньяга килә. Мәрьям аны биләүгә биләп, терлекләргә ашарга салына торган утлыкка яткыра.



Шул тирәләрдә генә ул төнне берничә көтүче көтү көтә.  Раббының бер Фәрештәсе алар янына килеп, күңелле хәбәр җиткерә.



“Бүген Давыт шәһәрендә сезнең өчен Коткаручы туды, Ул – Мәсих, Раббы!  Сез Баланы табарсыз, Ул биләүгә биләнгән булыр һәм утлыкта ятар”, - дип әйтә.



Кинәт кенә тагын бик күп нурлы фәрештәләр килеп чыга. Алар: “Күкләрдәге Аллаһыга дан! Аллаһы илтифат күрсәткән кешеләргә Җирдә иминлек!” - дип кабатлыйлар.



Көтүчеләр ашыга-ашыга ат абзарына юнәлә.  Баланы күргәч, алар Гайсә турында фәрештәләрдән ишетелгәннәрне барлык кешеләргә сөйли.





Кырык көн узгач, Йосыф белән
Мәрьям Гайсәне Иерусалимдагы
Аллаһы йортына алып
килә.  Шимун атлы
тәкъва һәм диндар
бер кеше Бала өчен
Аллаһыга шөкер итә
һәм, һәрвакыт ураза
тотып, дога кылып,
көне-төне Аллаһы
йортында хезмәт итә
торган карт Ханна да
Аллаһыга шөкер итә.



Алар Гайсәнең Аллаһы Улы, вәгъдә ителгән Коткаручы булуы турында белә. Йосыф ике кошны корбан итә. Аллаһы кануны буенча, фәкыйрь кешеләр баланы Раббыга багышлау өчен шундый йола үтәргә тиеш була.

Берникадәр вакыт узгач, үзенчәлекле бер йолдыз көнчыгыш иленнән аксакалларны Иерусалимга



китерә. “Яңа туган яһүдләр Патшасы кайда? Аңа табыну өчен сәҗдә кылырга дип килдек,” диләр алар.

Һируд патша бу аксакаллар турында ишетеп хафага төшә.  Ул, Гайсәне тапкач, миңа да хәбәр итегез, ди аларга.  “Мин дә Аңа сәҗдә кылырга барыр идем,” дип әйтә. Ләкин ул алдаша. Һируд Гайсәне үтерергә тели.



Йолдыз аксакалларны сабый бала белән Мәрьям һәм Йосыф яшәгән йорт янына алып килә.  Юлчылар, сәҗдә кылып, Гайсәгә алтыннан һәм хуш исле майлардан бүләкләр бирә.



Аллаһы бу картларны, яшерен генә кайтыгыз, дип кисәтеп куйган була. Һируд нык ярсый. Гайсәне үтерергә теләп, мәкерле идарәче Бәйтлехемдәге барлык ир



балаларны үтерә.



Ләкин Һируд Аллаһы Улына зыян китерә алмый! Төшендә кисәтү алган Йосыф Мәрьям белән Гайсәне ышанычлы урынга, Мисырга алып китә.

Һируд үлгәч, Йосыф Мәрьям белән Гайсәне алып, Мисырдан кайта.



Алар Гәлиләя диңгезеннән ерак булмаган, кечкенә генә Насара шәһәренә барып урнашалар.

Гайсә Мәсихнең тууы

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Маттай 1-2, Лүк 1-2

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып акыллыландыра.” Мәдхия 119:130

# Тәмам

36

60

Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)